Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

# КАРАР

2018 елның 13 ноябре № 30/5

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә, Чүпрәле районы прокуроры протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2016 елның 15 февралендәге 17/8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 18 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының 1 бүлегендә күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре бирүдә кызыксынучы гражданнарны исемлекләрдән төшереп калдыру һәм аларга җир кишәрлеге бирүдән баш тарту турында карар кабул итә:

1) гражданнарга әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пункты нигезендә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү;

2) Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү:

а) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;

б) Татарстан Республикасыннан даими яшәү урынына чыгу;

в) ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү, уллыкка алуны юкка чыгару, опеканы яисә попечительлекне туктату;

г) ата-ананың (ата-ананың) законсыз гамәлләре нәтиҗәсендә баланың (балаларның) үлеме;

3) гражданнар тарафыннан аларны исемлектән төшереп калдыру турында гариза бирү;

4) җир кишәрлеген сайлау процедурасында гражданнарның җир кишәрлеген сайлаудан өч тапкыр баш тартуы йә аларның җир кишәрлеген сайлау процедурасына өч тапкыр килмәве;

5) гражданнар исемлекләргә кертелгән документларда күрсәтелгән белешмәләргә туры килми торган һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында дәлилли торган белешмәләрне ачыклау.

Гражданнарга исемлекләрдән төшереп калдыру һәм җир кишәрлеге бирүдән баш тарту турында хәбәр итү, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып 7 көннән дә соңга калмыйча, заказлы хат белән йә аларга язма астына хәбәр бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

2) 19 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җир кишәрлеген аларга бирүдән баш тарту турында гражданнарга хәбәр итү, вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып 7 көннән дә соңга калмыйча, заказлы хат белән яисә аларга хәбәр бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров